ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән килешүләр, рәвешләр һәм тәртип буенча төзүчеләрнең үз йөкләмәләрен үтәү хакында алардан квартал саен хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык (шул исәптән еллык) хисабын алу;»;

б) бишенче абзацта «нигезләмәләренең» сүзен «таләпләренең» сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затларга Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый

актларын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларын, башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашырырга вәкаләтле федераль органының норматив хокукый актларын бозуларны бетерү турында күрсәтмәне» сүзләрен «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затларга Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль органының норматив хокукый актлары таләпләрен бозуны бетерү турында күрсәтмәне» сүзләренә алмаштырырга;

г) җиденче абзацта «акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүне гамәлгә ашыручы» сүзләрен «акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче» сүзләренә алмаштырырга;

д) тугызынчы абзацта «акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы» сүзләрен «акчаларын җәлеп итүче» сүзләренә алмаштырырга;

е) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затлардан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган белешмәләрне һәм (яисә) документларны «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән вакытта алу;»;

ж) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән критерийлар нигезендә акчалары күпфатирлы йортларны төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргәннәр дип тану һәм мондый гражданнарның реестрын алып бару.»;

2) 6 статьяның 2 өлешендәге $5^{1}$ пунктында «төзүчене» сүзен «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 65-ТРЗ